ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының 6 һәм 12 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 394-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының 6 һәм 12 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 394-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 22 феврале
№ 1856-VI ДС

проект

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинеты
тарафыннан кертелә

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**«Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының 6 һәм 12 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында**

**1 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» 2012 елның 25 декабрендәге 91-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 12 (II өлеш); 2014, № 7; Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2017, № 33 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 6 статьяның 4 пунктында «(әлеге Законның 12 статьясындагы 3 пунктында күрсәтелгән урыннардан гайре)» сүзләрен алып ташларга.

2) 12 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«12 статья. **Гавами чаралар уздыру тыела торган урыннар**

Гавами чаралар уздыру тыела торган урыннар Федераль закон нигезендә билгеләнә.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының 6 һәм 12 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектына**

# АҢЛАТМА

«Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының 6 һәм 12 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проекты «Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» 2012 елның 25 декабрендәге 91-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (алга таба – митинглар турында ТР Законы) «Җыелышлар, митинглар, урам йөрешләре һәм пикетлар турында» 2004 елның 19 июнендәге 54-ФЗ номерлы Федераль законга (алга таба – митинглар турында Федераль закон) 2022 елның 5 декабрендәге 498-ФЗ номерлы Федераль закон белән кертелгән үзгәрешләргә туры китерү максатыннан эшләнгән.

Митинглар турында Федераль законның 8 статьясы анда җыелышлар, митинглар, урам йөрешләре, демонстрацияләр үткәрү тыела торган урыннар исемлеге белән тулыландырылды. Митинглар турында Федераль закон белән мондый урыннарга кертелгән:

1) елга, диңгез, тимер юл һәм автомобиль вокзаллары һәм станцияләре, аэропортлар, диңгез, елга портлары, пристань биналары һәм территорияләре;

2) белем бирү оешмалары, медицина оешмалары, халыкны социаль яклау оешмалары биналары һәм территорияләре, балалар һәм спорт мәйданчыклары;

3) гавами хакимият органнары биналары, шулай ук мондый биналар, яшәешне тәэмин итү объектлары, шул исәптән электр, җылылык, суүткәргеч челтәрләр, су белән тәэмин итү һәм (яки) пычрак суларны агызу челтәрләре, газ белән тәэмин итү челтәрләре эшчәнлеген тәэмин итә торган объектлар янындагы территорияләр;

4) гыйбадәтханәләр, дини биналар һәм корылмалар, шулай ук мондый биналар һәм корылмалар урнашкан җир участоклары.

Элегрәк Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнгән җыелышлар, митинглар, урам йөрешләре, демонстрацияләр уздыру тыела торган урыннарны өстәмә билгеләү хокукы аныкланган. Бу очракта Россия Федерациясе субъекты законы белән җыелышлар, митинглар, урам йөрешләре, демонстрацияләр уздыру тыела торган урыннарның урнашу урынын күрсәтүче адреслы яки башка ориентирлар билгеләнергә тиеш. Бүгенге көндә республика территориясендә вәкаләтле органнарның фикерен исәпкә алып мондый өстәмә урыннарны билгеләү актуаль түгел.

Митинглар турында ТР Законына әлеге үзгәрешләргә бәйле рәвештә түбәндәге үзгәрешләр күздә тотыла: җыелышлар, митинглар, урам йөрешләре, демонстрацияләр үткәрү тыела торган урыннар исемлеге төшереп калдырыла,

гавами чаралар уздыру тыела торган урыннар Федераль закон нигезендә билгеләнә дигән нигезләмә билгеләнә.

ТР Законының 6 статьясына үзгәреш 12 статьяга кертелгән үзгәрешләр белән бәйле һәм техник характерда.

**«Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының 6 һәм 12 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

# ИСЕМЛЕГЕ

«Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының 6 һәм 12 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 28 маендагы «Гавами чара үткәрү тыелган биналар һәм башка объектлар янындагы территорияләрнең (җир кишәрлекләре) чикләрен билгеләү турында» 336 номерлы карарына үзгәрешләр кертүне таләп итә.

**«Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының 6 һәм 12 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектын**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законының 6 һәм 12 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.